ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.02.2021 г. Заинск № 92

**«Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 16 апрелендәге 791 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2001 елның 15 гыйнварындагы 7507 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучылар булу һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге под-1326/20 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының "Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында" 2021 елның 15 гыйнварындагы 04/13-06/94 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында» 2020 елның 21 гыйнварындагы 567/21 номерлы хаты нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 16 апрелендәге 791 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 01 мартындагы 334 номерлы, 2018 елның 25 июнендәге 1036 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.12 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә «Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алучылар булу һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге под-1326/20 номерлы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгын Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

юрист
И.П.Фәттахова
7-12-31